КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 26 ноябрь г.Казань № 998

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итүне оештыру һәм башкару турында

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 26 маендагы 310 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә юкка чыгару максатлары өчен алынган хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция кыйммәтен хайваннар һәм (яки) хайваннардан җитештерелгән продукция хуҗаларына каплау тәртибен раслау турында» 2018 ел, 14 февраль, 84 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә кош гриппының югары патогенлы вирусы чыганаклары барлыкка килүне булдырмау һәм аларны бетерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Писмән авыл җирлегендә шәхси ярдәмче хуҗалык территориясе чикләрендә хайваннарны һәм (яки) хайваннардан алынган продукцияне 54.563612° төньяк киңлеге һәм 52.640502° көнчыгыш озынлыгы географик координаталарыннан 200 метр радиусында алып юк итүне үткәрергә.

2. Бу락карарга теркәлгән Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продукциясен алып юк итү буенча махсус комиссия составын расларга.

3. Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итү буенча махсус комиссиягә әлеге карарның 1 пунктында каралган чараларның үтәлешен билгеләнгән тәртиптә оештырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 26 ноябрь, 998 нче
карары белән расланды

Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итү буенча махсус комиссия составы

| | |
|---|---|
| Латыйпов Солтан Сәлим улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең терлекләрдә йогышлы авырулар һәм эпизоотиягә каршы чараларны оештыру бүлеге башлыгы, махсу комиссия рәисе |

Махсус комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтов Рашат Хәмит улы | «Лениногорск район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы |
| Галимуллин Айрат Наил улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә караган Түбән Кама территориаль ветеринария иминлеге һәм дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы |
| Шәмәрданов Илнур Әбдрәүф улы | Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча). |

___